Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

№642

Менделеевск ш.

11.11.2020

Менделеевск шәһәре территориясендә
су белән тәэмин итү һәм
ташландык суларны агызу өлкәсендә
гарантияле оешма турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законның 6 һәм 12 статьяларындагы 1 өлешенең 2 пункты белән, Менделеевск шәһәре территориясендә үзәкләштерелгән, тиешле һәм өзлексез су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызуны оештыру максаты белән һәм «Татгазэнерго» ЯАҖен үзгәртеп коруга бәйле рәвештә «Газпром теплоэнерго Казан» ҖЧҖнә барлык хокукларны һәм бурычларын тапшырып үзгәртеп кору рәвешендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск шәһәре территориясендә салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә гарантияле оешманы «Газпром теплоэнерго» ҖЧҖ билгеләргә

2. ҖЧҖ «Газпром теплоэнерго Казань»:

- кулланучыларга салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызу) тәэмин итү.

- Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә абонентлар белән тиешле һәм өзлексез салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суларны агызу эшләрен башкаруга шартнамәләр төзергә.

3. Әлеге карарны «Менделеевск яңалыклары» газетасында бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 11 сентябреннән 76 нчы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы С.В.Метальников

Төзелеш һәм ТКХ бүлеге башлыгы П. А. Лизунов